<table>
<tr><td>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЧЕРЕМШАНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>СОВЕТ ЛАШМАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ул.Советская дом 55А, село<br>Лашманка, 423110</td><td></td><td>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЛАШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br>Советлар урамы,55А йорт,<br>Лашман авылы, 423110</td></tr>
<tr><td colspan="3">тел./факс +7(84396) 2-92-35 email: Lash.Cmn2@tatar.ru</td></tr>
</table>


№108 18 декабрь 2023 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Лашман авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 июнендәге № 86 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Лашман авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 декабрендәге № 86 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1.1. Нигезләмәнең 4.13 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «4.12. Класс чины бирү көне дип класс чины бирү турында карар кабул ителгән көн санала».

1.2. 4.19 пунктны төшереп калдырырга.

1.3. 4.21 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында карар, Нигезләмәнең 4.15 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чинын бирү турында барлык кирәкле документлар белән органга яки җирле үзидарәнең класс чинын бирергә вәкаләтле вазыйфаи затына тапшыру турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Лашман авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: Р.Г.Фәттахов